ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.7 һәм 5.8 статьялар өстәргә:

«5.7 статья. **Урамда йөрми торган транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу**

1. Урамда йөрми торган транспортның күчмә составын һәм урамда йөрми торган транспорт инфраструктурасы объектларын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән урамда йөрми торган транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәмәгән өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

вазыйфаи затларга кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик

затларга – ике йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

5.8 статья. **Урамда йөрми торган транспорттан файдалану кагыйдәләрен бозу**

Урамда йөрми торган транспортның күчмә составын һәм урамда йөрми торган транспорт инфраструктурасы объектларын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән урамда йөрми торган транспорттан файдалану кагыйдәләрен үтәмәгән өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.9 статья өстәргә:

«7.9 статья. **Урамда йөрми торган транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урамда йөрми торган транспорттан файдалану кагыйдәләрен үтәүгә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы**

1. Урамда йөрми торган транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм урамда йөрми торган транспорттан файдалану кагыйдәләрен үтәүгә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы әлеге Кодексның 5.7, 5.8 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инженер-инспекторы, аның урынбасары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.6» цифрларыннан соң «, 7.9» цифрларын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ өлеш өстәргә:

«$12^1$. Әлеге Кодексның 5.7, 5.8 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең вазыйфаи затлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 31-ТРЗ